**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
«23» май 2022 ел

КАРАР
№ 534

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чара күрсәтү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясындагы 2 өлеше, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, балалары булган аерым категория гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар күрү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында ата – аналардан (законлы вәкилләрдән) балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен алына торган түләү, аларның берсе генә булса да, Россия Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча бүлеге хезмәткәре булган очракта, ата-аналарга (законлы вәкилләргә) билгеләнгән күләмнән 25 процентка кимрәк алыначак, диеп билгеләргә.

2. Гаиләдә берничә ташламага хокук булганда ата-аналар (законлы вәкилләр) сайлавы буенча бер ташлама кулланылырга тиеш.

3. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУсына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чыгымнарны 2022 елга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетында каралган акчалар чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә әлеге карарда күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын оештыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән балалар йөри торган муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1) ата – аналардан (законлы вәкилләрдән) ата-ана түләве күләмен киметү турында, Россия Эчке эшләр министрлыгының Хезмәт таныклыгының (алга таба- раслый төрган документ) күчермәләре белән бергә, гаризалар кабул итү эшен оештырырга;

2) әлеге карарда күрсәтелгән ярдәм чараларын күрсәтү максатларында, Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Нурлат районы буенча бүлеге хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балалары саны даими мониторинг алып барырга.

6. Ата-ана түләвенең күләме тиешле нигез булган чорга кими. Ата-ана түләве күләмен киметү яки киметүдән баш тарту турында карар мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан гариза һәм раслый торган документның күчермәләре кергән көннән алып 3 эш көне эчендә кабул ителә. Ата-ана түләве күләмен киметүдән баш тарту турындагы карар тиешле карар кабул ителгәннән соң 3 эш көне эчендә гариза бирүчегә язмача җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр бирү ата-аналар түләве күләмен киметүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүче мәктәпкәчә белем бирү оешмасына гариза һәм баланы мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул иткәндә, шулай ук ата-ана түләве күләмен киметү өчен нигез барлыкка килгәндә раслый торган документның күчермәсен тапшыра.

Ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан расланган документлар тапшырылмаган очракта, ата-ана түләве тулы күләмдә түләнә.

Ата-ана түләвенең кимүенә китерә торган шартлар туганда, ата-аналар (законлы вәкилләр) бу хакта күрсәтелгән шартлар туганнан соң 1 эш көне эчендә мәктәпкәчә белем бирү оешмасына хәбәр итәләр.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм аның гамәлдә булуы 2022 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин